ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.11.2024 ел Баулы шәһәре №165

2025 елга Баулы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау Программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелек) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү (зарар китерү) куркынычларын профилактикалау программасын контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 990 карары белән, «Баулы муниципаль районында автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында» Баулы муниципаль район Советының 2022 елның 27 октябрендәге 141 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2025 елга Баулы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалауның кушымтада бирелә торган программасын расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 12 ноябрендәге
165 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

2025 елга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау
ПРОГРАММАСЫ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2025 елга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль өлкәсендә закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасы «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы карары белән расланган, закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасын контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан эшләү һәм раслау Кагыйдәләре нигезендә,
оешмалар һәм гражданнар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең намуслы үтәлешен стимуллаштыру, мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яисә) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зыян) китерергә мөмкин булган шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү, контрольдә тотылучы затларга мәҗбүри таләпләрне җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында хәбәрдарлыкны арттыру максатларында эшләнгән.

1.2. Программа Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү (зарар китерү) куркынычларын профилактикалау чаралары комплексын күздә тота.

1.3. Муниципаль контроль төре: автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль.

1.4. Муниципаль контроль предметы: Баулы муниципаль районы территориясендә гражданнар һәм оешмаларның (алга таба – контрольдә тотыла торган затларның) автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге өлкәсендәге мәҗбүри таләпләрне үтәве:

1) автомобиль юлларына карата билгеләнгән:

а) гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүленгән полосаларында һәм (яисә) юл буе полосаларында урнашкан юл сервисы объектларын эксплуатацияләүгә;

б) автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү өлешендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма юл корылмаларын (юл-төзелеш материалларына һәм эшләнмәләренә таләпләрне дә кертеп) капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тәртиптә тоту эшләрен гамәлгә ашыруга;

2) автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметына карамаган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга карата билгеләнгән.

1.5. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль район Советының 2022 елның 27 октябрендәге 141 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы территориясендәге автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмә нигезендә, муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы орган булып, Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты тора (алга таба — Башкарма комитет).

Автомобиль транспортында муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар булып, Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы һәм баш белгече (алга таба – автомобиль транспортында муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар) тора. Күрсәтелгән вазыйфаи затларның вазыйфаи бурычларына, аларның вазыйфаи инструкцияләре нигезендә, автомобиль транспортында муниципаль контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру керә.

1.6. Контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларны үтәү дә муниципаль контроль предметы булып тора.

1.7. 2025 елга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау кысаларында Башкарма комитет тарафыннан түбәндәге чаралар гамәлгә ашырыла:

1) Баулы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында үтәлешен бәяләү муниципаль контроль предметы булган мәҗбүри таләпләр булган норматив хокукый актлар исемлекләрен яисә аларның аерым өлешләрен, шулай ук тиешле норматив хокукый актлар текстларын урнаштыру;

2) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча белешмәләр эшләү һәм бастырып

чыгару, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре аша мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыру.

## 2. Программаны гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары

2.1. Профилактик эшләрнең максаты булып тора:

1) барлык контрольдә тотылучы затларның мәҗбүри таләпләрне намуслы үтәвен стимуллаштыру;

2) мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яисә) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерергә мөмкин булган шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;

3) контрольдә тотылучы затларга мәҗбүри таләпләр җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында хәбәрдарлыкны арттыру;

4) контрольдә тотылучы затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу ихтималына китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерүне дә кертеп, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү;

5) контрольдә тотылучы затларга административ йөкләнешне киметү;

6) закон белән саклана торган кыйммәтләргә китерелә торган зыян күләмен киметү.

2.2. Профилактика эшенең бурычлары булып:

1) мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау системасын ныгыту;

2) мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау, мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар эшләү;

3) карала торган хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә оешмаларның һәм гражданнарның хокукый аңын һәм хокукый культурасын күтәрү.

## 3. Профилактика чаралары исемлеге, аларны үткәрү сроклары (ешлыгы)

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль район Советының 2022 елның 27 октябрендәге 141 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы территориясендәге автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмә нигезендә, түбәндәге профилактик чаралар уздырыла:

| Чара атамасы | Чараның эчтәлеге | Чараны гамәлгә ашыру срогы |
|---|---|---|
| 1. Мәгълүмат бирү | Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча тиешле белешмәләрне урнаштыру юлы белән Баулы муниципаль районының рәсми сайтына хәбәр итү | даими |

| | | |
|---|---|---|
| 2. Хокук куллану практикасын гомумиләштерү | Үткәрелгән контроль чаралар һәм аларның нәтиҗәләре турында белешмәләрне җыю һәм анализлау юлы белән хокук куллану практикасын гомумиләштерү. Хокук куллану практикасын гомумиләштерү йомгаклары буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган доклад әзерләү, ул контроль органы җитәкчесе тарафыннан раслана | ел саен хокук куллану практикасын гомумиләштерү елыннан соң килүче елның 30 гыйнварыннан да соңга калмыйча |
| 3. Кисәтү игълан итү | Башкарма комитетта мәҗбүри таләпләрне бозулар турында белешмәләр булган очракта һәм (яисә) мәҗбүри таләпләрне бозуның закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүе йә закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы тудыруы турындагы белешмәләр расланмаган очракта контрольдә тотылучы затка мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамавы турында кисәтү игълан итү | законнарда каралган нигезләр барлыкка килгән саен |
| 4. Консультация уздыру | Телдән яисә язма рәвештә телефон аша, видеоконференцэлемтә аша, шәхсән кабул иткәндә, профилактик чара, контроль (күзәтчелек) чарасы барышында консультация бирү | контрольдә тотылучы затларның һәм аларның вәкилләре мөрәҗәгатьләре буенча даими |
| 5. Профилактик визит | Контрольдә тотылучы затның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча профилактик визит рәвешендә йә видеоконференцэлемтә ярдәмендә профилактик әңгәмә. Профилактик визит барышында контрольдә тотылучы зат үз эшчәнлегенә йә аңа караган объектларга карата мәҗбүри таләпләр турында хәбәр ителә | елына бер тапкыр |

Баулы муниципаль район территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру

кысаларында профилактик чаралар үткәрү буенча җаваплы вазыйфаи затлар булып, Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы һәм баш белгече тора.

4. Программаның нәтиҗәлелек күрсәткечләре

| № п/п | Күрсәткеч атамасы | Күләме |
|---|---|---|
| 1. | «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2021 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, Баулы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүматның тулылыгы | 100% |
| 2. | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган докладны раслау, аны бастырып чыгару | үтәлгән / үтәлмәгән |
| 3. | Әзерләнә торган мәҗбүри таләпләрне бозулар яисә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында расланган белешмәләр булган мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча һәм мәҗбүри таләпләрне бозуның закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүе йә закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы тудыруы турында расланган мәгълүматлар булмаган очракта кисәтүләр өлеше ( % ) | 20% һәм күбрәк |
| 4. | Консультация сорап мөрәҗәгать иткән затларның гомуми санында, консультация бирүдән канәгать булган затлар өлеше | 100% |

___________________________________